## САНАГАННЫ ЯРАТА

Хөкүмәт йортында алты айга бюджет үтәлешен тикшерделәр

> 2



## ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

Гомерендә бер китап та укымаган кеше ике китап укый алмаячак...

> 3

## КӨРӘШЧЕЛӘР НӘСЕЛЕ

Авылдашларыңны якыннанрак беләсең килсә, авыл тарихын барларга кирәк икән

> 3

## ИСӘНМЕСЕЗ! ЗЕЧБУРЕСЬ!

«Ватаным Татарстан» – удмурт авылында

> 4


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 107 (28880) | Чәршәмбе | 27 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131


Гөлгенә ШИҺАПОВА

Көнүзәк мәсьәлә

# СУ КИЧЕРМИ... ХАТАЛАРНЫ

**Республика сулыкларында батучылар саны арта. Ел башыннан Татарстанда 47 кешенең гомере суда өзелгән. Аларның 39ы коену сезоны башлангач батып үлгән, сигезе – балалар. Көннәр эссе торгач, соңгы ике-өч көндә күңелсез хәбәрләрне күп ишеттек. Татарстанның кече суднолар буенча баш дәүләт инспекторы Юрий Венедиктов сүзләренчә, күңелсез очракларның күбесе тиешсез урыннарда су коену аркасында килеп чыккан.**

mchs.tatarstan.ru

– Татарстанда 50 пляж эшли. Ел саен берничә районда яңа коену урыннары булдырабыз. Быел 10 яңа пляж ачылды. Кешеләр күбрәк коенган урыннарны җиһазландырып, су керергә яраклы итәбез. Республиканың 15 районында пляж бөтенләй юк. Аның каравы һәр районда бассейн бар, – дип сөйләде Юрий Венедиктов Министрлар Кабинетында узган брифингта.

Ә кешегә сулык кирәк! Ул бассейнга гына риза түгел. «Коенырга ярамый» дигән язулар да туктатмый аларны. Батасын белсә, кеше су янына килмәс иде. Әмма берәү дә суга исән чыкмам дигән уй белән керми шул. Минзәлә районының Иске Иркәнәш авылына кунакка кайткан Рүзәл дә тиз генә әйләнеп кайтам дип чыгып китә. 14 яшьлек малайның үлеме бөтен республиканы тетрәндерде. Авыл халкы, әле дә бу хәлгә ышанмыйбыз, ди.

– Шулкадәр акыллы бала иде ул. Әти-әнисе аерылышкач, гел авылда булды. Каникул саен бабасы Хәмзә белән әбисе Флера янында иде. Үзебезнең малай иде инде. Барыбыз өчен дә авыр хәл. Әле дә елыйбыз. Якыннарына бигрәк авыр. Әнисе ничек түзәдер?! – диде исемен әйтергә теләмәгән җирле үзидарә хезмәткәре. – Ул көнне аларга кунак егете кайткан булган. Бер дә су коенырга барганы булмаса да, Рүзәл никтер бу туганы белән күлгә киткән. Коенып чыгарга уйлагандыр инде. Әмма йөзә белмәгәч, бата башлаган. Туганы кычкырган тавышка ерак түгел генә утырган балыкчылар килгән. Ул арада Рүзәл су астына киткән була инде. Кунак егет балыкчылардан телефон алып торып, 112 хезмәтен чакырткан. Рүзәлне Иске Иркәнәш авылына җирләделәр. Әнисе Юлиянең бердәнбер баласы иде. Ничекләр бу хәсрәт белән яшәр инде?!

Көннәрнең эссе торуы халыкны суга тарта. Ни өчен батабыз соң? Белгечләр күп кешенең суга исерек килеш керүен, кайберәүләрнең йөзә белмәвен әйтә. Йөзә белмәү дигәннән, инде ничә еллар коткаручылар да бу хакта сөйли. Һәр ата-ана баласын йөзәргә өйрәтергә тиеш, ди алар. Заманча мәктәпләрдә йөзү түгәрәкләре эшли, бассейннар бар. Мамадыш районы башлыгы Анатолий Иванов инде ничә еллар районда яшәүче һәр балага бассейннарда йөзәргә өйрәнергә мөмкинлек бирә. Махсус график буенча һәр көнне балалар бакчасыннан һәм мәктәп укучыларын бассейнга йөртәләр икән. Аларны мәктәп автобуслары алып килә. Иң ерак авыллар да читтә калмый. «Мамадышта сулыклар күп. Күңелсез хәлләр килеп чыкмасын өчен, һәр бала кечкенәдән йөзә белергә тиеш», – ди Анатолий Иванов.

Мамадыш районының Кече Кирмән мәктәбендә укучы Алия Гыймазова уку елында ай саен районга бассейнга йөри икән. «Безне тренерлар өйрәтә. Суда үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында сөйлиләр. Бату куркынычы булганда, нишләргә икәнен аңлаталар. Йөри торгач, йөзәргә өйрәндек инде. Бассейнда бар да җайлы. Судан курыкканнар йөзәргә өйрәнгәнче саена керә, остаргач, тирәнендә шөгыльләнә башлый. Сыйныф белән баргач, рәхәт. Ярыша-ярыша йөзәбез», – ди Алия.

Күп кенә әти-әниләр балаларын түләп бассейнга йөртә. Казанда яшәүче Гөлшат Сафиуллинаның ике баласы да атнага икешәр тапкыр йөзәргә йөри икән.

– Диңгезгә җыенабыз. Балалар анда рәхәтләнеп йөзсен өчен, сентябрь аенда ук бассейнга язылдык. Балалар укыган мәктәп иске, янәшәдәгесе әле өч ел элек кенә төзелде. Анда бассейн бар. Бер дәрес 250 сум тора. Тренерыбыз хатын-кыз. Шулкадәр ипле итеп аңлата. Берничә төрле итеп йөзәргә өйрәнделәр. Сөенеп бетә алмыйм. Баланы йөзәргә өйрәтү – әти-әнинең бурычы бит инде ул, – ди Гөлшат.

Әмма бар ата-ана да бертөрле уйласа иде ул. Балаларының кайда йөргәнен белмәүчеләр дә бар икән. Юрий Венедиктов әйтүенчә, үзләре генә су кереп яткан 11 баланың әти-әнисенә беркетмә төзеп, 5 мең сум штраф салынган.

Ахыры 2 нче биттә >

## Җире бар, йорты да булыр

Татарстанда төзелеш өчен өстәмә 30 җир кишәрлеге әзерләп куелган. Шулай итеп, торак төзү өчен яраклы кишәрлекләр саны 64кә җиткән. Росреестрның республика буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, аларның гомуми мәйданы – 240 гектар. Җир кишәрлегенең 30ы – шәхси торак йортлар, өчесе күпфатирлы йортлар төзү өчен билгеләнгән. Күпчелеге (52се) Питрәч районында урнашкан. Калганнары – Түбән Кама, Арча, Аксубай, Актаныш, Яшел Үзән, Нурлат, Югары Ослан һәм Кукмара районнарында.

## *Кызыл китап калыная*

Россиянең яңартылган Кызыл китабына югалу куркынычы янаган тагын 158 җәнлек төре кертелгән. Россия табигать ресурслары һәм экология министры Александр Козлов әйтүенчә, узган гасыр ахырында, 20 ел эчендә беренче тапкыр буларак, Кызыл китаптан 122 төр төшереп калдырылган, шул ук вакытта яңа 158 төр кертелгән. Хәзерге вакытта китапта саклау таләп ителгән 443 төр җәнлек һәм кош урын алган. Моннан тыш министрлык үсемлекләр буенча Кызыл китапны яңарту буенча эш башлап җибәргән. Аны киләсе елда яңадан бастыру күздә тотыла.

Министр сүзләренә караганда, сентябрь аенда Камчаткада Кызыл китапка кертелгән шоңкарларны (кречет – бөркеткә охшаш кош) үрчетү үзәге ачылачак. Шулай ук Дагыстан тыюлыгында бөркетләр семьялыгына керүче балабан һәм курганниклар үзәге булдырылган.

## Болгарда – «Кара пулат»

Композитор Эльмир Низамовның «Кара пулат» операсы янә тамашачы хозурына чыгарыла. Ул 12–13 августта Болгар шәһәрендә ачык һавада күрсәтеләчәк. Әсәр Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу хөрмәтенә кире кайта. Опера 2015 елда Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев җитәкчелегендәге «Яңарыш» фонды ярдәмендә сәхнәгә куелган.

Премьераны 7 ел элек башкарган күп кенә артистлар хәзер дә уйнаячак. Арада яңа исемнәр дә бар. Төп рольләрне Илүсә Хуҗина, Артур Исламов, Илгиз Мөхетдинов, Денис Ханбаба башкара. Либретто авторы – Татарстанның халык шагыйре, Россия Дәүләт премиясе лауреаты Ренат Харис. Режиссер-куючысы – Татарстанның халык артисты Георгий Ковтун.

Яңалык

# Август үзгәрешләре

**Эшләүче һәм эшләмәүче пенсионерның акчасы арта, спорт белән шөгыльләнүчегә салым акчасы кире кайтарыла. 1 августтан гамәлгә керәчәк үзгәрешләрнең иң мөһимнәрен барладык.**

➤Эшләүчеләрнең һәм узган елда эштән туктаган пенсионерларның пенсиясе арта. Әмма күпкә түгел. Өстәмә, хезмәт хакы күләменә карап, узган елда тупланган баллардан чыгып исәпләнә. Пенсионер күп дигәндә өч баллга исәп тота ала. 1 пенсия баллы – 118 сум. Шуңа пенсия күләме күп дигәндә 354 сумга гына үсә. Ә эшләмәүче пенсионерларга килгәндә, 80 яшькә җитүчеләрнең, шулай ук быел июльдә I группа инвалидлык алучыларның пенсиясе 7200 сумга артачак. Калган пенсионерларныкы үзгәрешсез кала.

➤Спорт белән шөгыльләнүчеләргә түләнгән салым акчасының бер өлеше кире кайтарылачак. Фитнес өчен тотылган чыгымның максималь күләме – 120 мең сумның 13 проценты кире бирелә. «Вычет»ның иң зур күләме 15600 сум тәшкил итә. Ләкин бу сумманың башка социаль «вычет»лар (әйтик, уку, дәвалану өчен) белән бергә исәпләнүен искәртергә кирәк. Спорт «вычеты», 2022 ел йомгаклары буенча, 2023 елда бирелә башлаячак. Аны үзең өчен дә, балалар өчен дә алып булачак.

rg.ru

➤«Иннополис» махсус икътисади зонасында IT-үзәк төзеләчәк. Татарстанда «Иннополис» территориясен киңәйтү турында карар кабул ителгән. Аңа Казанның Совет районындагы 1,38 гектар мәйданда җир кишәрлеге кертелгән. Шушы өстәмә җирдә IT-үзәк калкып чыгачак. Анда мәгълүматларны саклау һәм чит ил программаларын урнаштыру буенча өч компания-резидент эшләячәк.

➤Дәүләтнең оборона куәтен ныгыту һәм дәүләт иминлеген үстерү өчен төзелгән контрактлар буенча сатып алынган товарга, башкарылган эшкә түләү срогы билгеләнә. Ул товарны (эшне) кабул итеп алганнан соң 30 көннән дә артмаска тиеш.

➤Ерак Көнчыгышның икенче гектары. «Дальневосточный гектар» программасында катнашып, биредәге җирләрне уңышлы гына үзләштерүчеләр 1 августтан тагын бер кишәрлек алырга мөмкин. Июль аеннан бу программа Арктикага да кагыла.

➤Ау һәм хайваннар дөньясы турында законга үзгәрешләр кертелә. Хәзер төбәкләр Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы белән килештергәннән соң гына рөхсәт ителгән ау төрләрен, вакытын, ау коралын һ.б. билгели алачак. Россиядә 3 ел буе ау хайванының ниндидер төре саны 50 процентган күбрәккә кимесә, аны аулау тыела. Шулай ук илдә хайваннар дөньясының дәүләт кадастры турында нигезләмә кертелә.

➤ОСАГО рәсмиләштерүдә үзгәреш. 22 августтан башлап автомобиль хуҗалары ОСАГО килешүен төзегәндә транспортка техник карау уздыру турында документ тапшырудан азат ителәчәк.

➤Тавышлы рекламаны тыю. 25 августтан биналар түбәләре, диварларда урнаштырылган тавыш җиһазлары-көчәйткечләрдән файдаланып, тавышлы реклама куллану тыела. Кешеләрнең тынычлыгын саклау өчен эшләнелә бу.

Сүзгә-сүз

**Игорь КРАСНОВ, Россия генераль прокуроры:**

Россиядә халыкка социаль ярдәм күрсәтү системасы камилләштерелә: эшләмәүче пенсионерларга өстәмә түләүләр, балалы гаиләләргә акчалата ярдәм күрсәтелә, ана капиталы акчасын файдалану мөмкинлекләре артты. Шулай да, прокуратура күзәтчелеге тәҗрибәсе күрсәткәнчә, халык федераль һәм төбәк ташламалары, матди һәм башка ярдәм чаралары турында хәбәрдар түгел. Барлык социаль ярдәм чараларын берләштергән бердәм портал булдырырга кирәк.

**(Ведомствоның Телеграм-сәхифәсеннән)**

## РОССИЯДӘ – КОРОНАВИРУСКА КАРШЫ ВАКЦИНАЦИЯ

**«Зарплата.ру» тикшеренү үзәге белгечләре Россия халкының коронавируска каршы вакцинага мөнәсәбәтен сорашкан.**

ВАКЦИНА ЯСАТАСЫЗМЫ?

**36%** >> кабат прививка кадатырга җыена

**9%** >> тәүге тапкыр прививка кадата

НИ СӘБӘПЛЕ?

**45%** >> яңа вируслардан курку

**33%** >> кешеләр белән даими элемтәдә булу

**8%** >> сәяхәт итү

## *Бензин тиешенчә салына*

Татарстанда 800ләп ягулык салу станциясе бар. Аларда ягулыкның машина багына тиешенчә салыну-салынмавын Стандартлаштыру, метрология һәм тикшеренүләр төбәк үзәге («ЦСМ Татарстан») күзәтеп-барлап тора. Оешма елына бер тапкыр республиканың барлык АЗСларын тикшерә. «ЦСМ Татарстан» директоры урынбасары Сергей Иванов «Татар-информ» агентлыгына әйтүенчә, автомобильчеләргә АЗСларда ягулыкның салынып җиткерелү-җиткерелмәвенә борчыласы юк. «Бу мәсьәлә бик нык контрольдә тотыла. Күзәтчелек чаралары кимүгә карамастан, кулланучы безгә мөрәҗәгать итеп, үзенә нәрсәләрнең шикле тоелуы турында белдерергә мөмкин», – ди ул.

Аның әйтүенчә, АЗС эшендә теге яки бу чатаклыклар ачыкланса, зур штрафлар салына. Ягулык салу станциясе өчен штраф күләме – 500 мең сумнан, нефть эшкәртүче завод өчен 5 миллион сумнан башлана. Ә максималь штраф күләме – 55 миллион сум. Шул ук вакытта, белгеч билгеләп үткәнчә, машина йөртүче үзе генә ягулыкның тиешенчә салыну-салынмавын белә алмый. Моның өчен махсус үлчәгеч-савыттан файдаланырга кирәк. Ул һәр заправкада бар. Шуңа бензин салып, бу процессны видеога төшерергә һәм аны шикаятькә кушып тапшырырга кирәк.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

**Дөньяда**

## БАРМЫ СИН, ЮКМЫ, РЕЦЕССИЯ?

Дөнья икътисады авыр сулыш ала. Базарларның бикләнүе, энергия чыганакларына бәяләрнең кискен һәм күп тапкыр күтәрелүе, азык-төлек инфляциясе, гомумән, товарлар һәм хезмәтләрнең кыйммәтләнүе җитештерүчеләр өчен дә, кулланучылар өчен дә авыр проблемага әверелә. Биржа һәм криптотүнтәрелешләр утка ялкын өсти. Бюджетларын криптовалютапарга корган кайбер дәүләтләр бар. Аларга хәзер дефолт куркынычы яный. Зур халык күтәрелешләреннән курку проблемаларны яшерүгә, алар хакында «яңа тел» (новояз) белән сөйләшүгә китерә. Рәсми хакимиятләр киң массаларга хакыйкатьне белдерүдән курка, башларын комга яшерә. АКШның Финанс министрлыгы җитәкчесе ил икътисадының авыр хәлен «үсештән соң кирәк булган акрынаю» дип бәяләде. Байден да аңа ияреп, «рецессия куркынычы юк» дип тәкрарларга мәҗбүр булды. Чынлыкта, глобаль икътисад җитештерүне киметә, ике квартал рәттән кимү рецессия дип атала. Планетаның күпчелек төбәкләрендә инде икътисади проблемалар барлык тишекләрдән дә пар булып бәрә. Кытай югары квалификацияләр тозагына килеп капты. Илдә айтичылар кирәгеннән артык күп, ә менә эретеп ябыштыручылар җитешми. Яшьләр арасында эшсезлек 2017 елдан бирле даими рәвештә үсә һәм 19,3 процентка җитте. Бу – Җир шарындагы өченче күрсәткеч. Испания һәм Һиндстан гына яшьләр эшсезлеге буенча Кытайны узып киттеләр. Аларда бу сан – 27–28 процент. Һәр өч яшь кешенең берсе диярлек эшсез булган җәмгыятьне күз алдына китерегез. Икътисади үсешнең барлыгы-юклыгын шуннан чамаларга була. Эшсезлек чин яшьләрен дәүләт хезмәтенә урнашуга омтылдыра. Чиновникларның хезмәт хаклары чамасыз зур түгел, әмма тотрыклы эш урыны бу кимчелекне каплый. Си Цзиньпин кулына диплом алган яшьләрне бер сәгатьтә баю турындагы хыялларын онытып торырга чакырды.

Илдә хәлнең катлаулы булуын җинаятьчелек үсешеннән дә чамаларга була. Лос-Анджелес полициясе (АКШ) халыкны кыйммәтле бизәнү әйберләре тагып, яхшы машиналарда йөрмәскә чакырды. Димәк, аларда бездәге узган гасырның туксанынчы елларындагы базлыгыть чәчәк ата.

Мюнхендагы (Германия) Икътисади тикшеренүләр институты илдәге икътисади климат индексының биш пункта түбәнгә тәгәрәвен хәбәр итә. Агымдагы икътисади шартлар индексы да кискен түбәнгә сикергән. Икътисади тикшеренүләр институты президенты Клеменс Фуэст: «Германия рецессия чигендә тора. Энергиягә югары бәяләр һәм газ дефициты куркынычы икътисад җилкәсенә авыр йөк булып ятты», – ди. Илдә бәяләр болай да кушаклап чаба. Банкирлар көзгә аларның яңа кискен күтәрелешен вәгъдә итә. Электрга бәяләр күтәрелеше элеккеге капиталистик муллык җәмгыятьләрен дә аны куллануга башка күзлектән карарга этәрә. Швеция хөкүмәте энергетикларны криптовалютлар майнингы өчен күпме электр энергиясе китүен тикшерергә чакырды. «Безгә энергияне криптовалютлар җитештерүгә тотканчы, корыч коюко заводларын тәэмин итү мөһимрәк», – диләр хөкүмәттә.

**Россиядә**

## ЗӘҢГӘР ЯГУЛЫК САТУНЫ ТУКТАТАБЫЗ, ИНЕРТ ГАЗЛАР СӘҮДӘСЕНӘ КҮЧӘБЕЗ

Европаның энергетик проблемалары Россия газы белән бәйле. Мәскәү, төрле сылтаулар табып, Көнбатышка табигый газ озатуны нык киметте. Бу – аның санкцияләргә җавабы. Я санкцияләрне алаcыз, я ягулыксыз каласыз дигән иштә. Ва-банкка бару, ягъни Көнбатыш белән мөнәсәбәтләрдә соңгы уен картасын чыгарып салу ни дәрәҗәдә отышлы булыр, әлегә әйтү кыен. Кремль европалыларның Украинага хәрби ярдәм күрсәтүләрен дә газ басымы ярдәмендә туктатырга тели. Моңа бирелерләрме-юкмы икәнен якындагы килачәк күрсәтер. Евросоюз әлегә горур торырга ниятли. Германия Россия газының 6–8 процентын азык-төлек калдыкларыннан һәм тирестән биогаз алып капларга җыена. Моның технологияләре бар, ләкин проектның кайчан тормышка ашырыласы мәгълүм түгел. «Газ сугышы» чын мәгънәсендә кискен бара. Ике як та югалтулар белән исәпләшмәскә ниятли. Россиягә кулләп углеводородлар сату агымдагы хәлдә кирәк тә түгел, чөнки алмашка товар алу мөмкинлекләре чикләнгән. Чит илләргә контейнерлар белән озаткан товарларга да җавап итеп товар кайтарып булмый әле. Контейнерлар киткән илләрендә утырып калалар. Буш килеш контейнер ташып булмый бит инде. Нәтиҗәдә илдә контейнер проблемасы баш калыкта.

Табигый газ урынына инерт газлар җитештереп, тышкы базарларга чыгу стратегик юнәлешкә әйләнеп бара. Баксаң, бу өлкәдә дә Россия лидер була ала икән. Путин хөкүмәт әгъзалары белән соңгы утырышта нәкъ менә инерт газлар белән сәүдә итү перспективасын тикшерде. Неоннан башка, мәсәлән, смартфон, автомобиль һәм башка техника өчен микроэлектроника җитештерү мөмкин түгел. Бу чималның 30 процент запасы – Россиядә, әмма ил дөнья базарында бер процент кына неон сәүдәсен тота. Вице-премьер Мантуров Путинга Бауман исемендәге Мәскәү дәүләт техникум университетында неон җитештеру җайга салынуын һәм ел ахырына глобаль базарның 10 процентына тиң булган 70 мең тонна неон җитештерелә башлачагын әйтте. Киләсе елга исә неон җитештеру халыкара базарның чирек ихтыяҗы күләмендә булачак икән. Ксенон һәм криптон газлары белән глобаль базарның 30 процентын яуларга ниятлиләр. Дөрес, санкцияләр сәбәпле, тышкы базарларга чыгу катлаулы, әмма газларны кулланыла торган әзер продукция дәрәҗәсенә җиткерү планнары да бар.

Киңәшмәдә гелий хакында сүз ишетелмәде. Әмма яңа технологияләр өчен котылгысыз кирәк булган бу газга дөнья базарында кытлык. Амур газ эшкәрту заводы тулы куәтенә эшли башлагач, Россиядә гелий җитештерү 13 тапкыр артачак. Гелийны иң күп экспортлаучы илләрнең берсе – АКШ сентябрьдән тышкы базарларга аны сатуны туктатачак. Бу Россия газы өчен перспективаны арттыра. Гелий 5G технологияләре өчен котылгысыз әһәмиятле, атом-төш реакторларын суытуда, лазер һәм чиста металлар җитештерүдә дә кулланыла. Глобаль базарда аны иң күп кулланучы – Кытай, ул ярты базарны алып тора.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

**Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка «Татнефтехиминвест-холдинг» җәмгыятенең Директорлар советы утырышында берничә инновацион проект тәкъдим иттеләр.**

Казан федераль университетының фармацевтика фәнни-белем бирү үзәге директоры Юрий Штырлин Россиядә ярымпродуктларны читтән кертүне алыштырырлык җитештерүне булдырырга тәкъдим итте. Болар – азык-төлек сәнәгате, машина төзелеше, төзелеш һәм нефть тармагы, атом энергетикасы өчен кирәкле булган кушылмалар. Моннан тыш фармацевтика тармагына бәйле алмашлар табу да зарур. Юрий Штырлин нефть, газ, химия комплексы предприятиеләре белән хезмәттәшлекне җайга салырга тәкъдим итте. Ә менә фәнни-техник яктан мәгълумат белән ярдәм итүне КФУ һәм республиканың башка югары уку йортлары үз өстенә алыр иде.

Татарстан Президенты әлеге тәкъдимгә карата:

– Федераль штаб аша эшләргә кирәк, җитештерүче зыян күрергә тиеш түгел. Федераль дәрәҗәдә ярдәм алу өчен проектның нигезле булуы мөһим, – диде.

2024 елга Татарстанда экологик полимер – ксантанлы сагызы (ксантановая камедь) җитештерә башламагайлары. Ул Россиядә беренче булачак. Әлеге чималны нефть җитештерү, азык-төлек һәм косметика сәнәгатендә кулланалар. Әлегә бу чималга ихтыяҗны импорт белән каплыйлар.

Республиканың кайбер җитештерү тармаклары катализатор һәм химик реагентларны чит илдән кайтарту аркасында авырлык кичерә. Бу исә автомобиль, полимер, медицина эшләнмәләрен чыгаруны куркыныч астына куя.

– Катализаторлар – безнең авырткан урыныбыз. Киенлыклар булачак, шуңа күрә нидер эшләргә, бу проектка ярдәм күрсәтү юлларын табарга кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

***

**Киңә Хөкүмәт йортында «Татнефть» җәмгыятенең Директорлар советы утырышы узды. Әлеге утырышта советның яңа рәисен сайладылар. Әлеге вазыйфаны кабат Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов башкарачак. Моннан тыш утырышта Директорлар советы каршындагы комитетларның рәисләре расланды.**

Утырышта катнашучылар 2022 елның беренче яртыеллыгында бюджет үтәлеше нәтиҗәләре турында хисап тыңлады, агымдагы елның август аена бюджетны раслады һәм «Татнефть»нең агымдагы эшчәнлегенә кагылышлы башка мәсьәләләрне карады.

Утырышта сүз «Татнефть»нең кадрлар резервын булдыру нәтиҗәләре турында да барды. Әйтик, компаниядә яшьләрнең сәләтләрен ачыклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән программа-проектлар гамәлгә ашырыла. Мәсәлән, ел саен үткәрелә торган TatneftTechCupChallenge чемпионаты, халыкара нефть-газ форумы, һөнәри осталык бәйгеләре һәм башка ярышлар.

# САНАП ТОТКАННЫ ЯРАТА

## ХӨКҮМӘТ ЙОРТЫНДА АЛТЫ АЙГА БЮДЖЕТ ҮТӘЛЕШЕН ТИКШЕРДЕЛӘР

**Акча эше дисциплина таләп итә. Хәзерге катлаулы шартларда бигрәк тә. Хөкүмәт йортында беренче яртыеллыкта республиканың берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары буенча республика киңәшмәсендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шул хакта искә төшерде.**

tatarstan.ru

Утырышта яңгыраган мәгълүматларга караганда, ярты елда Татарстанның тупланма бюджетына 230,5 млрд сум акча кергән. Шуларның салым булган кеременәре – 207,3 млрд сум. Шул рәвешле салым җыю буенча план 61,4 процентка үтәлгән. Узган елгы күрсәткечләрне хәтердә яңартсак, тупланма бюджет үтәлеше 125 млрд сумны тәшкил иткән иде. Салым һәм салым булмаган керемнәр хисабына казнага 149 млрд сум акча кергән.

Әмма, Президент әйтүенчә, быелгы күрсәткечләр тынычландырырга тиеш түгел.

– Хәзерге сәяси вазгыятьтә безнең предприятиеләргә басым ясала. Икътисади үзгәртеп кору бара. Җитештерүчеләр логистиканы җайга сала, импорт алмаштыру ысулларын эзли, курс үзгәреше шартларында эшли, – дип ассызыклады Рөстәм Миңнеханов. Бу җәһәттән Президент тармак министрларына әлеге мәсьәләләрдән һәрвакыт хәбәрдар булып торырга чакырды. – Җитештерүчеләргә кооперация элемтәләре урнаштырырга һәм сату базарларын табарга, хәзер гамәлдә булган ярдәм чараларын кулланырга, яналарын федераль дәрәҗәдә тәкъдим итәргә булышырга кирәк. Без бердәм команда булып эшләргә тиеш.

Хәзерге шартларда катгый финанс дисциплинасы гаять мөһим, дип искәртте Татарстан Президенты. Акча таләп иткән юнәлешләр дә, ирешәсе күрсәткечләр дә байтак.

Алты айлык акча хәлләре турында Россия салым хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе башлыгы Марат Сафиуллин да хисап тотты. Идарә җитәкчесе белдергәнчә, Татарстан Идел буе федераль округында салым керемнәре күләме буенча алдынгы булды. Икенче урында – Самара өлкәсе (497 млрд сум), өченче урыны Пермь крае (455 млрд сум) били.

– Беренче алты айда республикада салым җыю 634,6 млрд сумга җитте. Бу узган елгы күрсәткечтән 32 процентка күбрәк. Җыелган салымның 416,6 млрд сумы – федераль, 218е Татарстанның тупланма бюджетына күчерелде. Былтыргы күрсәткечтән 44 процентка артыграк бу, – диде идарә җитәкчесе.

Кыскача әйткәндә, июнь аенда бюджетка 32,9 млрд сум акча күчкән (45 процентка якын 10,2 млрд сумга күбрәк). Аерым алганда, файдалы казылмалар чыгару тармагыннан килгән салым күләме – 407,2, НДС – 121,4, керемгә салым – 114,6 һәм физик затларның керемнә салым 47 млрд сумны тәшкил иткән. Физик затлар керемнә салымны кире кайтару күрсәткече дә 1,8 тапкыр артып, 10,8 млрд сумга җиткән.

Марат Сафиуллин белдергәнчә, салым кереме кимегән тармаклар да бар. Болар – нефть продуктлары җитештерү (0,3 млрд сум), автотранспорт чараларын җитештерү (2 млрд сум).

Татарстанның финанс министры Радик Гайзатуллин сүзләренчә, барлык дәрәҗәдәге бюджетларның керем өлешенең үтәлеше уңай бәяләнә.

– Республиканың үзкеремнәре буенча бюджет – 181,5, җирле бюджет 25,8 млрд сумга үтәлде. Яртыеллыкта күчкән акцизлар күләме 19,8 млрд сумны тәшкил итте, – дип хисап тотты министр.

Радик Гайзатуллин үз чыгышында бюджетка түләүләрне шактый киметкән компанияләрне дә (аларның саны 560лап) атады. Предприятиеләрнең матди кимүләре берничә йөз миллион сумнар белән исәпләнә. Гомумән кушсаң, 10 млрд сум акча дигән сүз бу.

Моңа Татарстан Президенты да игътибар итте. Күзәтү, тикшеру генә түгел, аларга ярдәм итү юлларын да барларга кирәклегенә басым ясады ул. «Ниндидер сәбәпләр бардыр, гел дә начар эшләгәннән генә түгелдер. Хезмәт коллективларын сакларга һәм яңа сату базарларын табуда булышырга кирәк», – диде Президент.

# Су кичерми... хаталарны

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Әти-әниләр җәйге чорда игътибарлы булсын иде. Кайберләре үзләре белән балаларын ияртеп килеп тә, кәеф-сафа корып утырып, кем белән килгәннәрен дә оныталар. Кисәтү, әйрәтү җитми. Дөрес, коткаручылар су янындагы кешеләр белән дә, мәктәп укучылары белән дә һәрдаим дәресләр үткәрә, аңлату эшләре алып бара. Әмма бу бик аз. Бала суда коену кагыйдәләре хакында кон саен ишетеп торырга тиеш. Батмас әле дип кенә уйларга ярамый, – ди ул. – Кече көймәләргә утырганда да тиешле таләпләр үтәлми. Коткару жилетын кияргә ашыкмыйлар. Бер мисал китереп үтәм. Пермь өлкәсендә ике балалы гаилә көймәдә йөрмәкче була. Әтиләре жилет киеп тормаска куша. Тик хәсрәт шундук эзләп таба үзләрен. Бер бала белән әти-әнисе суга бата. Кечкенә кызлары бу хәлләрне күреп тора. Сабый көймәдә 1,5 сәгать ярдәм көтеп утыра.

Баш инспектор, күпме сөйләсәң дә, халык битарафлык күрсәтә дигән фикердә. Хәтта суга батучыларны күреп тә, читтә калучылар бар, ди ул. Кыш көннәрендә юка бозга керүчеләрне күреп хәбәр итсәләр, суга батучыларны күрмиләрме шунда. Ә суга бата башлаган кеше үзе берничек тә ярдәмгә чакыра алмый икән.

– Беренче мизгелләрдә үк аның әченә су керә. Шуңа күрә бу эшне чит кешеләр, янында булучылар башкарырга тиеш. Кешеләр хәтта 112 телефонына хәбәр бирә белми, – ди баш инспектор. – Бер урында 3 ел эчендә ике кеше батты. Юкса, шул күлдә кеше батканын белгәч, кермәскә генә бит инде. Әмма кешеләр бөтенләй башкача уйлый. Ык елгасында да яшүсмерләр бату беренче очрак түгел. Әле шушы көннәрдә Әлмәттә, шәһәр ярында, 16 яшьлек кыз су астына китте. Янәшәдә яшьтәшләре дә булган. 16 яшь дигәч тә, аларда бала акылы әле. Алар үзләренең гомерен коткарыр өчен берниндә карар кабул итә белми. Бу кыз йөзә дә белгән, әмма елганың тирән өлешенә эләгеп, аска төшеп киткән. Яшьләр иптәшләре алдында үзләрен дә күрсәтергә тели. 18 яше тулмаганнар арасында исерткеч эчемлекләр куллананучылар да бар. Ни кызганыч, моның ахыры аяныч тәмамлана.

Исерткеч эчемлек дигәннән, сулыкларда батуның бер сәбәбе ул. Салган килеш коенырга керүчеләр арасында авырулары кузгалучылар да, көзән җыеручылар да очрый. Шуңа да коткаручылар, аек булмасаң, су янына якын да килмәскә куша. Махсус рейдлар вакытында исерек хәлдәге 25 кешегә беркетмә төзелеп, штраф салынган.

– Штраф белән генә кешене куркытып булмый. Һәркем үз гомерен үзе сакларга тиеш. Әгәр инде көймә-теплоходларда йөрисез икән, бу очракта йөртүче сезнең өчен җавап бирә. Җилетсыз кермәскә кирәк! Суга керсәң дә, көймәгә утырсаң да, таләпләр үтәлергә тиеш. Су хаталарны кичерми. Шуны онытмагыз, – ди Юрий Венедиктов.

**Суда үзеңне ничек тотарга?**

- ✓ Рөхсәт ителмәгән урынга йөзеп кермәскә;
- ✓ су кертергә йөрт хайваннарын алып килмәскә;
- ✓ суда йөрүче транспортка якын килмәскә;
- ✓ исерек килеш суга кермәскә;
- ✓ балаларны ялгыз йөртмәскә;
- ✓ кабартылган матрас белән суда йөзмәскә;
- ✓ үзең ясаган көймәдә йөрмәскә;
- ✓ туңмаска һәм эсселәнмәскә;
- ✓ батучы кеше күрсәгез, бу хакта хәбәр итәргә.

# КУЛЫҢ ЭШ БЕЛСӘ...

**HeadHunter хезмәте мәгълүматларына караганда, узган елның июнь ае белән чагыштырганда, быел Татарстанда эш эзләүчеләрнең саны 20 процентка арткан. Сез эш урыныгыздан канәгатьме? Без төрле һөнәр ияләренә әнә шул сорауны биреп, фикерләрен белештек.**

Илдар Мөхәммәтҗанов

**Камил КӘРИМ, язучы:**

– Унсигез яшьтә чын-чынлап эшли башладым. Чутлап карасаң, 55 елда дүрт эш урыны алыштырганмын. Су скважиналары бораулаучының язучы булып китүе читтән караганда сәер булса да, иҗат кечкенәдән үк «борчыды» мине. Мәктәптә укыганда ук газета-журналларга хатлар яза идем. Соңыннан үзем дә «Яшь ленинчы»да эшли башладым. Үсешемнең бер баскычы булды ул. Аннан Язучылар берлегенә «эләктереп» алдылар. Матур әдәбиятны пропагандалау бюросы хезмәткәре булдым. Берлекнең ул чактагы рәисе Туфан Миңнуллин «китәм» дигәч, башка эш урыны караштыра башладык. Шунда мине «Чаян» журналына чакырдылар. 12 ел бик рәхәт эшләдек анда. Ничек кенә булса да, «работа» сүзенең тамыры – «раб», ягъни кол бит. «Чаян»да мин үземне колга санамадым. Соңгы эш урыным «Казан утлары» журналы булды. Анда төп-төгәл 20 ел эшләдем. Шул елларда ныкытып иҗат эшенә тотындым. Ягъни, күргәнегезчә, туп-туры килеп кермәдем. Иҗат юлы туры булырга тиеш тә түгел ул. Бер урында гына эшләсә, кеше мукләнә, эшен «автомат» рәвештә башкара башлый. Шуңа да мондый юллар узганыма һич үкенмим.

**Алинә ГАЛИМҖАНОВА, фронт-менеджер:**

– Мин – студент, укуымны эш белән бергә алып барам. Ике еллап фронт-менеджер, администратор вазыйфаларын башкарам, социаль челтәрләрдә сәхифәләр алып барам. Минемчә, эш урыны ул гел алыштырып тора торган әйбер түгел. Бер эшкә кергәч, аннан китеп, яңа эшкә ияләшергә кыендыр ул. Эш урынымнан да, хезмәт хакымнан да канәгать. Баштарак кыен иде, бәлки җитмәгән вакыт та булгандыр. Әмма кайсы җирдә эшли башлагач үк миллионнар түлиләр?

**Дмитрий РОМАНОВ, такси йөртүче:**

– Такси йөртүче булып 10 еллап эшлим. Кечкенә бизнесым да бар. Анысын күптән түгел генә ачтым. Таксидан баш тартырга уйлаган идем инде, бер иянләнгән эш булгач, китәсе килми икән. Әлегрәк төзелеш өлкәсендә эшли идем, сәламәтлек какшагач, туктадым. Хәзер инде бер эшне икенчесенә дә алыштырасы килми. Эшемнән канәгать, хезмәт хакы да зарланырлык түгел. Улым менә бер урында берничә айдан артык тора алмый. Авыр, имеш. Җиңел эш юк инде ул. Яшьләр бик аңлап бетермиләр әле моны. Бер караганда, яраткан һөнәрләрен табарга тырышулары начар түгел инде. Ә без башкачарак тәрбияләнгән бит.

**Фәридә ЗӘКИЕВА, укытучы:**

– Университет бетереп, эшли башлавыма ике генә ел булса да, арыдым. Мәктәптә эш бик күп бит. Шәһәр мәктәбе булгач, балалар да күп. Кайчак, дөрес һөнәр сайладыммы икән, ялгышмадыммы, дип тә уйлап куям. Шуңа күрә башка өлкәдә дә эшләп карыйсым килә. Кем белә бит, күңел кушкан эшемне табып та куярмын. Әтиәнием бу фикеремне бик хупламый, куркалар. Шәһәр җирендә эш бетмәгән бит, дип тынычландырам инде үземне.

# «АЮ» НӘСЕЛЕ

**Авылдашларыңны якыннанрак беләсең килсә, авыл тарихын барларга кирәк икән. Көн саен диярлек моңарчы белмәгән, ишетмәгән яңалыкларга тап буласың.**

Салаватовлар гаиләсе белән дә шулайрак булды. Бездән ерак та түгел иде алар. Фирдәвес, Нурислам, Нурсәлим, Нургизәр исемле дүрт малай, алар янында иркәләнеп кенә йөргән Гөлнур исемле кызлары белән яшәп чирмәдә бергә тәгәрәшеп үстек. Хәер, иркәләнү сүзе дөрес үк булмас, кадерләү дигәне туры килер. Гөлнур эштән арынмады да кебек. Ни дисәң дә, хатын-кызлардан бөтерчек кебек әнисе Нурһәдия апа гына бит. Биш ир-атны ашатырга да, киендерергә дә кирәк, дигәндәй. Хәзер бу йортта абыйсы Нургизәр гаиләсе белән яши. Йорт бушап калгач, үзләре олыгая төшкәчтер инде, чит җирләрдән туган нигезгә – Яшел Үзән районының Айдар авылына кайтып урнаштылар.

Әтиләре Гафур абый бик оста куллы кеше иде. Монысы нәселдән килгән икән.

– Әтинең бабасы Гыймадиның бик зур биләмәләре, атлары, каралты-куралары булган, үзе балта остасы, ат арбасы көпчәге дә ясаган, – дип истәлекләрне барлый Гөлнур. – Бик куп заманнар үткәч тә, әле әни исән вакытта Кайбыч якларыннан берәү, монда элек көпчәкче булган, хәзер дә юкмы икән, дип сорап килгән. Гыймади бабайның улы Салават бабай да оста куллы булган. Таза гәүдәле, бик көчле кеше булган ул. Яшь чакта тәрле портларда йөк төяүче булып байларга эшләп йөргән. Ә Севастопольдә көчле һәм егәрлеге белән тарихка кереп калган Иван Поддубный белән бергә эшләгәннәр. Бабай 26 пот авырлык күтәрә алган. «Аю» кушаматы да шуңа тагылган. Ул үзе дини кеше булган. Рус телен дә яхшы белгән, чөнки Акъегет авылындагы Шафигуллин Заһидулла бай мәдрәсәсендә (соңрак ул рус-татар мәктәбе була) белем алган. Язган шигырьләре дә бар.

Нәсел тарихын барларга керешкән Гөлнур үзе күршедәге Бакырчы авылында яши. Шунда кияүгә чыгып, хәләл җефете белән балалар үстерәләр. Хәзер инде әби-бабай булу бәхетен татып, оныклар сөяләр. Шәҗәрә төзү турында аның үз фикере бар.

– Минемчә, нәсел шәҗәрәсен белү туган илгә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләргә, туганнарга, кардәш-ыругка, күрше-кулангә хөрмәт һәм кайгыртучанлык күрсәтергә кирәклеген искәртеп тора, – ди ул, без шәҗәрә төзергә соңгарак калдык шул, дип борчылып та ала. – Нәсел-ыру, туган-тумача турындагы истәлек-ядкарьләрнең еллар үткән саен никадәр

кыйммәтле буласын, әти-әниләр исән вакытта күбрәк белеп калырга кирәклеген аңламый калганбыз. Без бәләкәй чакларда әти безгә бабайларыбыз турында күп сөйли иде. Ләкин күбесе инде онытылган. Шулай да дүрт буын бабайның исемнәрен, ничек яшәгәннәрен беләбез әле.

Уйлап карасаң, Салаватовларның әле без таныш белгән әти-әниләре дә үзе бер тарих кебек. Гафур абый – Салават бабайның 1931 елда туган төпчек баласы. Бик зиһенле була ул. Әмма дүрт класс кына укып кала. Сугыш башлана. Малай 10 яшендә өлкәннәр белән бергә эшкә чыга. Илленче елларның урталарында Украинада хезмәт итеп авылга кайтканда, инде әти-әнисе шактый картайган, алар белән бергә йорт-җир дә шактый тузган. Егет озак уйлап тормый, нәселдән нәселгә килгән балта остасы һөнәренә керешә. Норлат авылыннан Нурһәдия исемле тегүче кыз белән тормыш корып җибәрә.

– Әни ел ярым Норлатка ательега барып эшләп йөри әле, – дип сөйли Гөлнур. – Ә төнлә лампа яктысында тагын тегү тегә. Телогрейка, арка җылысы сыра. Шул аяклы тегү машинасын Сылам авылы аша иңбашына күтәреп кайта. Ара шактый ерак бит инде. Алты чакрым тирәсе.

Гөлнур сөйләгәч, минем дә хәтерем яңарды. Нурһәдия апа безне дә киендерде бит. Барлыбызга да күлмәкләр тегеп бирде. Өйдә тегү машинасы булмагач, вак-төякләрне эшләргә дә әни аның янына йөрде. Чыннан да, никадәр әби-апаларны сөендергән ул. Кемнең чалбар балагын, кемнең пальто итәген кыскартасы бар – бар да Нурһәдия апага йөгерде.

– Әнием һәр Сабантуйга яңа күлмәк тегеп кидертә иде, – дип Гөлнур хәзер дә сөенә әле. – Ирләргә чәчәкле күлмәк модага кергәч, абыйларга да тегеп бирде. Өстәвенә колхозга эшкә дә йөрде. Ничек өлгергән икән ул? Шуңа хәзер дә шаккатам. Картайгач, әни миңа болай диде: «Кызым,

ШӘҖӘРӘ
«Ватаным Татарстан» газетасы һәм Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының уртак проекты

гомер буена кешегә тектем. Бер генә тукыма кисәген дә, кәтүген дә алмадым. Шүрәдә кайчак җеп кала иде. Үлгәч, шул җепне муеныма чорнарлар инде. Менә бер ак, бер кара кәтүк, шуны Мәфрүзә апаеңа сәдака итеп бир әле», – диде. Шөкер, бәхетле булды әни. Илебезнең төрле почмакларында хезмәт иткән дүрт улының да командирларыннан рәхмәт хатлары алырга насыйп булды. Аларны берәмтекләп җыеп барды, бик горурланды.

Әтиебез дә авылдашларга хезмәт итте. Безнең авылда әти кулы тими калган хуҗалыклар, мөгаен, бик аздыр ул. Бик тәгәл, пөхтә кеше иде. Аның эшләвен бик яраттылар. Йортлар төзүдән кала өстәл-урындыклар, шкаф-тумбочка, тәрәзә рамнары, йөзлекләре, чана-чаңгы, тагын әллә нәрсәләр... Әтинең колхозга да, хуҗалыкка да умарта оялары эшләгәне хәтердә. Без барыбыз да аңа булышабыз. Такталарны шомартабыз. Йомычка җыя-җыя, уйнарга да чыга алмаган чакларыбыз күп булды. Ул вакытта аңлап та бетермәгәнмен: алтын куллы кеше булган икән әтием. Сәгать тә төзәтә, итек тә ямый, хәтта кубыз да ясый иде ул. Салават бабам да кубыз ясаган. Өч, биш тиенлек акчалардан әбиләргә балдак та ясап бирә иде әле. Клубка бильярд таягы ясап биргәне дә хәтеремдә.

Көчле нәсел булгач, аңлашыла ки, Салаватовлар тирәюньдә көрәшчеләр буларак та дан тоттылар.

– Мин бәләкәйрәк чакта Сабантуйларда әтиемне мәйданга чыгарып, биленә сөлге бәйләргә тырышуларын һич тә аңламый идем, – ди Гөлнур. – Баксаң, ул яшь чакта батыр калып, көрәшеп йөргән икән. Аннан Нурислам белән Нурсәлим абыйлары да мәйданда көчләрен сынап карадылар. Нургизәр армиядән 1990 елда кайтты. Шунда беренче тапкыр көрәш мәйданына чыкты. Республикада дан тоткан Тау Иле авылы көрәшчесе Габбас Тимершин белән бил алышып, батыр асты калды. Бу аның өчен зур җиңү булды. Шуннан соң җиде ел бүе батыр исемен яулады. Олыгая төшкәч, эстафетаны улы Айнурга тапшырды. Ул, Яшел Үзән көрәш мәктәбендә шөгыльләнеп, яшьтәшләре арасында җиңүләргә лаек булды. «Яшел Үзән» газетасы призына оештырылган милли көрәштә бил алышып, абсолют батыр калды. Айнурның яулыйсы уңышлары алда әле.

Бәйрәмнәрдә, бигрәк тә Сабантуй көннәрендә көрәшче Салаватовлар тупланып үскән нигезгә җыелырга тырышалар. Балалар, оныклар белән. Нәсел җепләрен барлау өчен менә дигән җай бит инде. Сүз дә юк, Нурһәдия апа теккән күлмәкләр, бәлки, тузып та беткәндер, әмма авылдагы кайбер йортларда Гафур абый ясаган тәрәзә йөзлекләре бар әле. Иң мөһиме, гадел, намуслы, һөнәрле булулары белән аерылып торган бу кешеләр авылдашлары, балалары, оныклары күңелендә яши.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Шәҗәрәләр белән шөгыльләну һәм аны белү төркилардә, гарәпләрдә, германнарда киң таралган. Нәсел җепләре әле язу белән таныш булмаган гасырларда ук күп халыкларга мәгълүм була. Галимнәрнең язуларына карагаңда, Тын океан утрауларында яшәүче халыкларда хәтта 80 буынгача нәсел тарихларын белгән кешеләр бар икән. Иң элеккеге шәҗәрәләр күпмедер дәрәҗәдә энциклопедик характерда була: аларда тарихи мәгълүматлар белән берләттән халыкның көнкүреше, горефгадәте, фольклор – авыз иҗаты да чагылган.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**Түбән Камада яшәүче кадерле туганыбыз Наталья Николаевна ЛЕОНТЬЕВАга шушы көннәрдә 90 яшь тула.**

Наталья Николаевна – бөтен гомерен яшь буынны тәрбияләүгә багышлаган кеше. Балык Бистәсе районы Казаклар Чаллысы авылында туып-үсеп, башта озак еллар буе Мамадыш районы Албай авылында, шуннан соң Балык Бистәсе районы Котлы-Бөкәш авылы, Түбән Кама мәктәпләрендә балаларны рус теленә өйрәтте ул. Шушы төбәкләрдә аны белмәүче кешеләр сирәктер. Язмыш ташлаган соңгы яшәү урыны – Түбән Кама каласы урамнары буйлап Наталья апабыз белән янәшә атлаган чакларда моңа бигрәк тә нык инанасың. Элекке укучылары, хәтта аларның балалары сәлам бирмичә, хәл-әхвәлен белешмичә генә сөекле мөгаллимәләре яныннан беркайчан узып китми. Менә шундый мизгелләрдә бу тормышта чын укытучының тоткан урыны, аның нинди хөрмәтле һөнәр иясе булуын бөтен тирәнлеге белән аңлыйсың да инде.

Укымышлы, затлы, сөйкемле, итагатьле, сабыр, көчле рухлы Наталья апабыз, тугызынчы дистәне түгәрәкләсә дә, әле һаман бик тә кызыксынучан, тормыш сөючән кеше булып кала. Ил-дөнья хәлләре белән даими кызыксынып тора. «Ватаным Татарстан» газетасын күп еллар буе алдыра, андагы бер генә язманы да игътибарсыз калдырмый. Сәясәткә кагылышлы авыррак мәкаләләрне, кич утырганда, үз подъездында яшәүче ахирәтләренә дә рәхәтләнеп аңлата. Ә 86 яшькә кадәр бер ялгызы бакча тотуы, гомумән, Наталья Николаевнаның акыл ягыннан гына түгел, физик яктан да көчле, нык кеше булуын күрсәтә. Гомумән, безнең өчен һәрвакыт өлге булды һәм хәзер дә шулай булып кала ул.

Кадерле апабыз! Олуг юбилееӊ котлы булсын! Олыгайган көннәреңдә тән һәм җан сызлауларыннан башка гына, бәхет-шатлыкларга төренеп яшәргә, юбилейларыңны әле тагын да бәйрәм итәргә язсын!

Сине чиксез яратып, хөрмәт итеп һәм сиңа бары тик изге теләкләр генә теләп, барлык туганнарың

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Мин кулыма китап алам

# ӨЗЕЛМӘСМЕ АРА?

**Без «китап» дип сөйләшергә гадәтләнгәнбез инде. Моны берничек тә үзгәртеп булмыйдыр сыман. «Кеше хәзер китап укымый», – дип зарланабыз. «Юньле китап юк», – дип тә җибәрәбез. «Хәзер китап уку модада түгел», – дип тә өстибез. «Китап...» – дибез инде. Безнең өчен нинди дә булса текстны эченә алган, битләре билгеле бер тәртиптә бергә җыйналып төпләнгән бөтен басма да – китап. Чынлыкта да шулай инде ул. Ләкин болай дип сөйләшү халкыбызның бер әйтемен дә искә төшереп куя: сукыр тавыкка бар да бодай.**

Китап ул – гомум төшенчә. Аңа дәреслекләр дә, фәнни, мәдәни, әдәби, дини, фәлсәфи әсәрләр дә, башкасы да керә. Изге Коръәннең дә кайчагында «Китап» дип кенә атыйлар. «Китап сүзе» дигән тәгъбир дә шуның белән бәйле бугай.

Әле аның «әдәби китап» дигәне дә төрле төсмерләргә кереп ярылый, төрләргә, жанрларга бүленә. Чәчмә әсәрләрдән торган китап, шигырьләр, пьесалар җыентыгы. Балалар китабы. Чәчмә әсәрләр үзләре үк жанрлар буенча бүленә: детектив, фантастика, һоррор, мәхәббәт романы һ.б. Барысын да санап чыгу өчен генә дә хәтсез вакыт кирәк.

Соңгы елларда «файдалы китап», «зарарлы китап» дип бүлгәләү дә ешаеп китте. Зарарлыларына халыкның контрольдә тоту органнары тарафыннан экстремистик дип табылган язмалар керә. Аның өчен судка биреpгә дә, утыртып куярга да, төрле әзәрлекләргә дучар итәргә дә мөмкиннәр. Файдалыларына нәрсәләр керә торгандыр, мин бик аңлап бетермим. Бездә «социаль әһәмиятькә ия» дигәнрәк билгеләмә бар барлыгын да... Тик аның да чикләрен беркем дә аңлый алмый бугай. Югыйсә кешеләр укый ала торган һәрбер китап социаль әһәмияткә ия бит инде. Ул я сабак бирә, я гыйбрәт алдыра, яхшы китап икән, эзсез, нәтиҗәсез генә үтми.

Соңгы чорда «аудиокитап», «электрон китап» дигән төшенчәләр дә киң кулланышка кереп китте. Исеме яңа булса да, аудиокитап дигәне бүген генә туган нәрсә түгел инде, элек радиода «әдәби укулар» дигән рубрика бар һәм анда күренекле язучыларның кыныклы әсәрләрен тапшыралар иде. Адәм тавышы белән укылган китап инде ул, кыскасы. Хәтта борынгырак чорда, бөтен кеше дә укый-яза белми торган дәвердә, гыйлемлерәк затның ниндидер китапны уз иптәшләренә кычкырып укуын да «аудиокитап» дип атарга мөмкиндер.

Ә инде «электрон китап» дигәне соңгы вакытта гына, компьютерлар белән бергә киң таралды. Электрон китап ул – компьютер, телефон, ридерлар һ.б. китап уку җайланмаларында укырга яраклаштырып эшләнгән махсус файл. Аны кулда күтәреп йөртеп тә, гадәти почта аша китертеп тә булмый. Электрон китапханәләрдә яки китап кибетләрендә сатып алсагыз, ул сезнең электрон почтага килеп төшә һәм шәхси аккаунтыгызда йөкләү өчен сылтама пәйда була. Электрон китапларны дөньяның бер почмагыннан икенче почмагына мизгел эченә күчереп була. Ләкин бу да әр-яңа төшенчә түгел. Электрон китап идеясе 1930 елда барлыкка килә. Язучы Боб Браун, беренче булып, экраннан уку мөмкинлеге бирә торган җайланма Reader турында яза. «Бүгенге заман тизлегенә иярә алу өчен миндә үк машинасы булырга тиеш. Үземдә йөртеп, теләсә кайсы иске розеткага тыгып эшләтә ала торган гади уку машинасы. Бу машинада шрифтларны үзгәртеп, яктылыкны көйләп булырга тиеш...»

Менә шушыларны исәпкә алсаң, «Бүген китап укучы азайды», – дигән сүзләр беркадәр сәерләк булып яңгырый. Бер яклап ул дөрес тә кебек. Менә дәреслекләрне алыйк, алар да китап бит инде. Элек гаиләдә бишәр-алтышар бала үскән. Димәк, бер Әлифба китабын гына да һәр гаиләдән бишәр-алтышар кеше укыган дигән сүз. Хәзер гаиләдәге балалар саны уртача ике генә. Хәзер Әлифбаны ике генә бала укый. Димәк, китап укучылар саны өч тапкыр азайган булып чыга. Башка дәреслекләр белән дә шундыйрак хәл. Өстәвенә хәзер компьютерлар киң кулланышка керде, күп нәрсәләрне дәреслекләр буенча түгел, ә электрон вариантта интерактив рәвештә өйрәнәләр. Димәк, китап укучыларның күбәюе-азаюы демографик хәл белән дә бәйле. Сез күбрәк бала үстерәсез икән, китап укучылар да күбәячәк, балалар саны азая икән – китап укучылар да азаячак.

Тагы бер нәрсә бар. Хәзер технологияләр куз иярмәслек тизлек белән үзгәрә. Әйтик, интернет эшчәнлегенә бәйле китаплар – СЕО (сайтны эзләүчеләр аша таныту), СММ (социаль челтәрләр аша маркетинг) һ.б. шундый һөнәрләр буенча дәреслекләрнең бары тик электрон варианты гына актуаль була ала. Нәшриятларда кәгазь китап рәвешендә басылып чыкканчы алар инде искереп беткән була. Чөнки эзләүчеләр алгоритмнары үзгәрә, бүген иртән генә әйбәт эшләгән алымнар кичке якка инде мәгънәсен җуя. Шуңа күрә интернет технологияләр белән бәйле басма китапларның укучы

Илдар Мөхәммәтҗанов

ларын югалтуы бер дә гаҗәп түгел. Ләкин бу беркемгә дә «китап укучылар азая» дип әйтү хокукы бирми. Чөнки шул ук темага кагылган актуаль мәгълүматны кеше төрле сайтлар, электрон чаралар аша туплый. Бер сүз белән әйткәндә, бүген кеше актуаль мәгълүмат алуның барлык чараларын да куллана ала: видео һәм аудиоязмалар, текст һәм рәсем, инфографика... – барысы да кул астында һәм аның кәгазь китапка мохтаҗлыгы юк.

Хәтта тиз үзгәрми торган өлкәләрдә дә... Әйтик, әдәбият буенча осталыкны камилләштерү өлкәсендә роман, хикәя, сценарийлар язарга өйрәтүче әллә күпме онлайн-мәктәпләр бар. Анда бернигә көн шөгыльләнеп, бернигә дистә китап укып та, ала алмаган белемгә ия булырга мөмкин. Теорияне өйрәтәләр, гамәли күнекмәләр үткәрәләр, ахыр чиктә, нинди дә булса җитди әсәр язу кимәленә китереп җиткерәләр. Сәләте булган кешене, әлбәттә. Башка өлкәләрдә дә шундый ук мәктәпләр, семинарлар, вебинарлар эшли. Шулай булгач, кешенең үз һөнәре буенча китап уку ихтыяҗы да кими. Кими, дип әйтәм, юкка чыга, диясем килми, чөнки кайбер китаплар йөзәрләгән мәктәпне алыштырырга, өстәл китабы булып гомер буе яшәргә мөмкин.

Китерелгән мисалларның барысы да китап укучылар санын киметеп күрсәтүче нәрсәләр. Ләкин алар җәмгыятьнең түбән тәгәрәвен яки халыкның аң-гыйлемгә ихтыяҗы кимүне аңлатмый. Болар бары тик китапларда язылган белемне башка юсуллар белән алу мөмкинлеге дә барлыгын күрсәтә. Китап бүген гыйлем туплауның берләнбер чыганагы булудан туктады һәм аны укучылар саны азаю да – табигый күренеш.

> Китап укучылар кимүнең җәмгыятьтәге кимчелекләргә бәйле очраклары да бар. Менә безнең мәктәпләрдә бүген БДИ дип аталган нәрсә хакимлек итә. Ә ул бердәм дәүләт имтиханнарын тапшыру өчен китап уку, белем туплау бик мәҗбүри түгел. Тест рәвешендәге сорауларга җавап бирү өчен матур итеп сөйли белү дә, җөмлә төзү осталыгы да, фикер йөртү маһирлыгы да таләп ителми.

Гадиләштереп әйткәндә, син «әйе-юк» дип кенә торырга да мөмкинсең, алай диярга иренсәң, баш кагып-чайкап кына да җавап бирә аласың. Интеллектуаль кимлеге ике сүз яки ике хәрәкәт белән чикләнгән балага ни пычагыма кирәк ул китап? Кирәкми!

Бүген аңа хәтта белем дә кирәкми. Укуын кызыл дипломга тәмамласа да, аны яхшы урынга чакырып торучылар юк. Яхшы урынга эшкә керергә теләсә, аның кызыл дипломы түгел, ә дәрәҗәле чиновниклар белән бәйләнеше һәм шул йөнлы куллы абзыйларга бирерлек акчасы яки бүтән кирәкле нәрсәсе булырга тиеш. Нибары шул гына. Ә белем – икенчел урында.

Димәк, китап укучылар азаюның бүгенге сәясәт белән бәйле сәбәпләре дә бар. Ничек кенә әле! Менә мин авылда әле, кузәтеп яшим инде барысын да. Дөнья кисәк үзгәреп киткәч, авыл халкы күп итеп бәрәңге, суган утыртты. Ни булып бетәсен беркем дә белми бит инде, ә бәрәңгең бар икән, һич югы ачлыктан үлмисең. Хәзер менә бакчада яталар. Шуннан печәнгә чыгалар. Нәрсәдер сүтәләр, нәрсәдер төзиләр. Ә төзелеш кирәк-яраклары берничә тапкыр кыйммәтләнде. Башка нәрсәләргә дә хак артып кына тора. Хезмәт хаклары артмый, алар турында уйлап та бирүче юк. Менә шундый вазгыятьтә кеше китап турында уйлыймы инде? Беренчедән, 500–600 сумга китап алырлык акчасы юк аның. Икенчедән, вакыты юк. Хәтта вакыт таба алган очракта да китап сатып алырлык мөмкинлеге юк. Интернет аша кайтартсаң, икеләтә кыйбатка төшә, район үзәгендә китап кибете табармын димә, ә Казанга бару... «Ни сөйлисең, өч көн бүе тешем сызлап йөри, врачка да бара алмыйм әле...» Кайчагында миңа безнең илдә кешене китаптан, димәк, аң-белемнән, узаллы фикер йөртүдән биздерү сәясәте дә барадыр кебек тоела. Ялгышамдыр инде...

Китап кебек үк, кеше дә – гомум төшенчә. Мәктәпне тәмамлаганнан бирле бер китап та укымыйча әдәм булып йөрүчеләр дә бар. Өстән караучылар да җитәрлек. Үз наданлыгын, үз мескенлеген өстенлек итеп күрсәтүчеләр. «Бер китап укымасам да, мул тормышта яшим әле», – дип юана алар. Китапны буй җитмәслек биеклек итеп күрүчеләр бар. «Аңламыйм инде мин, аңлап укымагач, кызыгын тапмыйм», – дилә. «Кыйммәт, китап сатып алырга акчам җитми», – дип әйтүчеләр да бик күп. Мин боларны аңлап алам кебек. Мин бары тик: «Укырлык китап юк», – диючеләрне генә аңламыйм. Ну, берничек тә... Корьән укы... Ул – укырлык китап. Конституциягә укы – файдалы китап. Кызыклысы кирәк булса, Гиннесс китабын укы. Ләкин «укырлык китап юк» диючеләрнең күбесе дөньяда андый нәрсәләр барлыгын да белми бугай.

Нишлисең инде, гомереңдә бер китап та укымаган кеше ике китап укый алмаячак...

Марат КӘБИРОВ

# Исәнмесез! Зечбуресь!

## УДМУРТ

**Әгерҗе районында удмуртлар район халкының 6,4 процентын тәшкил итә. Без барып күргән Варкләд-Бодья авылында яшәүче әлеге милләт вәкилләре тормышка карашлары, гореф-гадәтләре, йолалары белән башкалардан шактый аерыла. Күпчелек бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре, тоткан кыйблалары бүгенгә кадәр кадерләнсә дә, телне саклау проблемасы аларда да бар...**

# ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ АВЫЛ

**Әгерҗе**

Авылның бик тә үзенчәлекле булуы аның керү капкасыннан ук шәйләнде. Агачка төрле сыннар уеп ясалган зур элмә тактага «Инмар мед утёз!» («Аллаһы Тәгалә сакласын!» – **Авт.**) дип язылган. Варкләд-Бодья авылының килеп чыгышы, тарихы XVIII гасыр ахырларына барып тоташа. Халкы сөйләвенчә, әби-бабайлары көчләп чукындырудан качып, Кече Пурга һәм Кече Бодья авылларыннан шушында килеп төпләнгән. Авыл атамасындагы беренче сүз елга исеме белән аваздаш булса, «Бодья» сүзе нәсел төркемен аңлата.

– Без христиан түгел. Тәре такмыйбыз, чиркәүләргә йөрмибез. Безнең үз динебез, үз Аллабыз бар. Без аңа Инмар дип эндәшәбез. Ин – күк, мар нәрсәдер дигәнне аңлата. Ягъни әлеге сүзгә күктә нәрсәдер дигән мәгънә салынган. Ир-атлар дога кылганда Аңа көньякка карап мөрәҗәгать итә. Бездә ислам, христиан диненнән аермалы буларак, язылган догалар юк. Һәркем күңелендәгесен укый, – дип аңлатты гомере буе шушы авылда яшәгән авылның иң хөрмәтле кешеләренең берсе Евдокия Михайлова.

Бүген авылда 280 кеше яши, аларның күпчелеге – өлкәннәр. Балалар бакчасы, башлангыч мәктәп, мәдәният йорты бар. Юллары, урамнары төзек, матур. Тик балалар саны гына аз. Укучылар һәм балалар бакчасына йөрүчеләр барысы бергә 25кә дә тулмый. Халыкның бер өлеше «Ак барс» агрофирмасында эшли.

– Заманында гөрләп торган алдынгы хуҗалык иде югыйсә. Яшьләр авылда калды, йортлар салды. Тулы бер урам барлыкка килде. Хәзер хәлебез авыр, хезмәт хаклары түләнми. Ир-атлар, алай гына да түгел, гаиләләр эш эзләп авылдан чыгып китте, йортларда әби-бабайлар гына утырып калды. Гаиләләре монда калганнар да вахта белән эшкә барып йөри. Ул елларда мәктәпкә 100 бала йөри иде, хәзер 12 укучы укый. Нишләп шулай килеп чыкты? Үзебез дә аптырыйбыз. Колхозлар яшәсә, хәлебез бу кадәрле үк яман булмас иде, дип уйлыйбыз, – ди алар.

Авыл халкының күпчелеге өлкәннәр дисәләр дә, терлек асраучы урта буын да шактый булып чыкты. Мәсәлән, Матвеевлар гаиләсе генә дә унбишләп мөгезле эре терлек асрый. Аларның алтысы – савым сыеры.

– Әлегә авыл халкы сөтлебикәләр асрап тормыш итә. Күрше-тирә авыллардан аермалы буларак, бездә маллар күп. Тик көтүче таба алмагач, берничә ел көтү чыкмый. Һәркем үзенекен үзе саклый, – ди алар.

### Бәйрәмнәре һәм йолалары

Варкләд-Бодья авылында яшәүче удмуртларның күпчелек бәйрәмнәре, йолалары безнең көннәргә кадәр сакланган. Шуларның иң зурысы – Быдӟым нунал бәйрәме. Ул русларның Пасха бәйрәменә охшаш булса да, аермалыклар да шактый. Әлеге бәйрәмне ир-атлар – аерым, хатын-кызлар аерым бәйрәм итә. Пәнҗешәмбе көнне югары сыйныфларда укучы егетләр махсус киемнәр киеп, авыл буйлап ит, ярма, май һәм йомырка җыя. Кичен исә алар махсус билгеләнгән изге урында үзләре генә учак ягып, ботка пешерә, догалар укый. Бу малайның егет булып җитлегүен белгертә. Дөрес, бу вакытта өлкән ир-атлар да аларга ярдәм итәргә мөмкин. Ял көне исә – кызларныкы. Алар да милли киемнәрен киеп, шушы ук юлны уза. Тик, егетләрнекеннән аермалы буларак, кызлар пешергән ботканы бөтен авыл халкы бергә авыз итә.

– Әйе, еллар узган саен авыл, кешеләр үзгәрде. Ләкин бәйрәмнең асылы, мәгънәсе һәм тәртипләре шул килеш калды, – ди Евдокия Михайлова. – Безнең тормышны бик күп галимнәр, тарихчылар килеп тикшерде, хәтта чит илләрдән килеп, киноларга кадәр төшерделәр. «Без кайсы ягыбыз белән башкалардан аерылып торабыз икән?» – дип аптырый идек. Чөнки безнең өчен ул – гадәти күренеш. Чынлыкта бу гореф-гадәтләрне башкалар үтәми икән.

Моннан кала, язгы кыр эшләреннән соң Гырон-быдтон, Гершыт, Гербер бәйрәмнәрен уздыралар. Алары безнең Сабантуйга охшаган. Шулай ук уеннар уйныйлар, җырлыйлар, бииләр. Ахырда ботка пешерәләр.

Бала тугач, мәет җирләгәндә башкара торган йолалары да үзенчәлекле. Мәсәлән, сабый бала беренче тапкыр әби-бабай йортына кунак булып кайткан көнне үрдәк яки каз чалып, аннан ботка пешерәләр. Шуннан соң гаилә башлыгы савытка ботка салып алып, ишегалдына чыга һәм Инмардан баланы ярлыкавын сорый.

Мәетне озату, җирләү һәм аны искә алу белән бәйле йолалары бигрәк тә үзенчәлекле. Әлеге авылда яшәүче удмуртлар мәрхүмне кием белән җирли. Табутка исә сарык йоны, мендәр, яфраклар, савыт-саба, тиен акча (анысы урын сатып алыр өчен кирәк), гигиена кирәк-яракларын, өстәмә киемнәрен сала. Әгәр, мәсәлән, ул җәен мәрхүм булса, ризык янына кышкы киемнәрен әзерләп салалар. Кышын вафат булса, җәйге киемнәрен куялар.

– Без, удмуртлар, бала туса да җырлап каршылыйбыз, мәрхүмне дә җырлап озатабыз. Кемдер: «Мине озатканда шушы җырны җырлагыз», – дип теләген әйтеп калдыра, – диләр.

Мәрхүмнең өчесен, җидесен һәм кырыгын уздыралар. Биш елдан соң аларны тагын бер тапкыр зурлап искә алалар. Мәрхүм ир-ат өчен ат башын, тоякларын, эчке органнарын пешерсәләр, хатын-кызга – сыер. Ягъни теге дөньяда ир-атка ат – эшләр, ә хатын-кызга сыер савар өчен кирәк.

Соңыннан сөякләрне изге урындагы су түбәнгә аккан урында үскән агачка алып барып элеп куялар.

– Кайвакыт мәрхүмнәр үзләре үк корбан сорап, якыннарының төшенә керә. Шулай ук гаиләдә бер-бер артлы бәхетсезлек булса яки һич көтмәгәндә маллар үлә башласа да, шушы ук йоланы башкарырга вакыт җиткәнлекне аңлата. Юл фаҗигасенә очрап, кеше һәлак булган урында да терлек чалына. Шуңа күрә удмуртларның оҗмах белән тәмугы юк. Аларда бу һәм теге як тормыш кына бар, – ди авыл халкы.

Моннан тыш, ир ягыннан туганнар җыелып, язын һәм көзен кисьтон (нәселдәге мәрхүмнәрне искә алу йоласы) башкара. Ул көнне табын кормыйча гына, камыр ризыклары пешерәләр, маңгайга йомырка бәреп ваталар. Шуннан соң ризыкларны ваклап, билгеле бер савытка салалар. Аларын ир-атлар изге урынга алып китә.

### Изге урыннар

Биредә яшәүче удмуртлар өчен иң кадерле җир – изге урыннар. Элек алар һәр ишегалдында булган. Хәзер авыл халкы өчен бердәм булган берничә шундый урын бар. Биредә яшәүчеләр җыелып, үзләренең йолаларын башкара, догалар кыла, терлек чала, ботка пешерә. Чит-ятларга, мал-туарга аяк атлап керү, әлеге урыннарны кадерсезләү, пычрату, агачларын, хәтта агач яфракларын өзү дә катгый тыела. Теләсә нинди көнне авыл кешесенең анда ялгызы гына барып йөрүе дә хупланмый. Шулай да Кунян кенер дип аталган изге урыннарын безгә дә алып барып күрсәттеләр. Анысы авылдан ерак түгел, агачлыкта урнашкан иде. Берничә җирдә учак эзләре, күк белән утны тоташтыручы символ – агач корылма, урындыклар бар иде. Биредә июньдә бар халык биш көн дәвамында дога кылу циклын башкарган. Беренче көнне мәрхүмнәрне искә алып, сарык чалганнар. Ак җәймә өстендәге савытка ипи, май алып килеп, шунда калдырганнар. Өченче һәм бишенче көнне – ботка, дүртенче көнне аш пешереп ашаганнар, тезләнеп дога кылганнар. Ризыкларны бары тик шушы җиргә табынучылар, ягъни шушы авылда туып-үскән кешеләр генә авыз итәргә тиеш икән. Әлеге йола ел да яңгыр, боз явуга карамыйча, билгеле бер көннәрдә уздырыла.

## Иң кадерле кунак

Удмуртларда иң кадерле, иң зур хөрмәткә ия кунаклар – ир ягыннан туганнар. Алар бөляк дип атала. Барлык бәйрәмнәргә, мәет озатуларга, туйларга, бәбигә исем кушу ашларына алар беренче булып чакырулы. Шуңа күрә удмурт хатын-кызы үз туганыннан бигрәк, иренең якыннары белән аралаша, йөрешә.
– Билгеле бер көнне шушы бөляк табын янына җыелып, догалар кыла. Без аны Вөсьнерге дип атыйбыз. Элек елына 3–4 тапкыр шундый утырышлар була торган иде. Хәзер ир-атлар Пасха көнендә генә җыелалар. Элек һәр бәйрәм Вөсьнергедан башлана иде. Йорттан йортка кереп, кунак булу, сыйлану – матур йола, – ди Наталья Матвеева.
Әниләренең кадерле истәлеге булып торган, буыннан-буынга әманәт итеп тапшырылган изүләрен дә бик кадерләп саклый удмурт апалары. Дөрес, элек әлеге калын тәңкәләр белән бизәлгән матур, затлы, шул ук вакытта шактый авыр бизәнгечне һәр бәйрәмгә кигәннәр, тик хәзер туйларга, зур чараларга гына тагалар.

**Сүзлек**

- ✓ Исәнмесез! – **Зечбуресь!**
- ✓ Кадерле дуслар! – **Гажано эшъёс!**
- ✓ Хәерле иртә! – **Бур ӵукнаен!**
- ✓ Хәерле көн! – **Зеч нуналэн!**
- ✓ Хәерле кич! – **Зеч жытэн!**
- ✓ Сау булыгыз! – **Зеч луэ!**
- ✓ Рәхмәт! - **Та́у!**
- ✓ Хәлләрегез ничек? – **Кыӵе тынад ужъёсыд?**
- ✓ Әни – **Анай**
- ✓ Әти – **Атай**
- ✓ Әби – **Песянай**
- ✓ Бабай – **Песятай**
- ✓ Мин сине яратам! – **Мон тонэ яратӥсько!**
- ✓ Мин Татарстанны яратам! – **Мон Татарстанэз яратӥсько!**
- ✓ Бәйрәм белән, дуслар! – **Праздникен, гажано эшъёс!**

## Милләтне тел яшәтә

Авыл, анда кайсы гына милләт вәкиле яшәсә дә, авыл инде. Үз мәшәкатьләре, үз куанычлары, үз проблемалары белән көн күрә. Варкләд-Бодья халкы әйтүенчә, соңгы 20–30 елда тормыш тамырдан үзгәргән. Моңа кадәр динне, йолаларны, тоткан кыйблаларын, телне саклап калыр өчен авылга хәтта чукындырылган кәләшләрне дә алып кайтмаганнар. Акрынлап бу язылмаган канун да җуелган. Хәзер авылда христиан динендәге хатын-кызлар да, балалар да күп.

– Моннан егерме-утыз еллар элек без әби-бабаларыбызның кагыйдәләрен, тәртипләрен тулысынча саклап яшәдек. Авылыбызда христиан динендәге бер генә кеше дә юк иде. Хәзер алай түгел шул. Бу мине бик борчый, әлбәттә, ләкин агымга каршы да барып булмый. Оныкларым арасында да христиан динендә булучылар бар. Кызганыч, миннән генә тормый шул, – дип көрсенеп куйды Евдокия Михайлова.

– Шул ук вакытта безнең дин беркемгә дә каршы килми. Әгәр изге урыннарыбызда дога кыласылары килә икән, беркемне дә читкә кагу юк, – дип өстәде Виктор Матвеев.

Варкләд-Бодья авылында өлкәннәр дә, яшьләр дә үзара удмуртча сөйләшә. Дөрес, кечкенә балалар арасында русча аралашучылар да бар.

– Авылда тел саклана әле. Тик бездән соңгы буын белән ни булыр? Әйтү читен, чөнки барысы да телефонда, ә анда – бөтенләй башка дөнья, – ди Наталья Матвеева. – Тиздән сабыйларның теле удмуртча түгел, инглиз телендә ачылыр, ахры. Әле ярый мәктәптә удмурт теле укытыла. Дәреслекләр белән дә авырлыклар юк.

Евдокия Михайлова сүзләренчә, традицияләр саклансын өчен милләтнең яшәве кирәк, милләт яшәсен өчен телне саклау мөһим.

– Мәҗбүриләп бернинди дә нәтиҗәгә ирешеп булмый. Кеше килгәч кенә «спектакль» дә куярга кирәкми. Барысы да гаиләдән башлана. Әгәр әти-әни гаиләдә үз туган телендә сөйләшә икән, бала да аны онытмаячак. Гореф-гадәтләр белән дә шулай ук. Мин аларның барысын да гаиләдә күреп үстем. Кечкенә вакытта әти артыннан кабатлау ошамый иде, ләкин алар барысы да минем күңелдә иң матур истәлек булып саклана, – ди ул.

Авыл халкы үз телләрендә газета-журналлар уку проблемасы барлыгын да әйтте.

– Без аларны атнага бер тапкыр Удмуртия башкаласы Ижаудагы редакцияләрдән алып кайтабыз. Күрше авылларга да таратабыз әле. Чөнки безгә басма матбугатны почта аша тарата алмыйлар, – дип аңлаттылар.

**Тәмле булсын!**

### Табань

Табань ризыгы мичтә пешерелә. Сөткә чама белән чүпрә, май, тоз, йомырка салып камыр басыла. Һәм шуны табага салып, ике ягын да кыздырып алалар. Табынга китерелгәч, өстенә тоз сибәләр һәм май белән майлыйлар. Шунысы игътибарга лаек: табаньны бары тик ир-атлар гына кисәкләргә бүлгәли. Табань янына табынга зырет дип аталган соус чыгарыла. Анысы бер стакан сөткә ике аш кашыгы он һәм бер йомырка, тоз, ак май кушып тугланган, каймакны хәтерләткән соус.

### Шунянь (чөгендерле балан пирогы)

4 стакан он, бер йомырка, бер стакан сөт һәм тәменчә тоз кушып, камыр басалар. Эчлеген түбәндәгечә ясыйлар. Баланны җыеп югач, шикәр, коры кесәл яки манный ярмасы белән болгатып, пешереп аласы. Шуңа чөгендер кушасы. Анысын кемдер пешереп, кемдер чи килеш кыргычтан кырып сала.

Сәхифәне Зөһрә САДЫЙКОВА әзерләде.
Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ фотолары.

**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Тираж – 6640 данә**
**Гомуми тираж – 16052 данә**

**Газетага сертификат бирелде** Заказ 307

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
**www.vatantat.ru**
**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**
**89179270040**
**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+